РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» август 2019 ел г. Альметьевск № 1594

Әлмәт муниципаль районы
башкарма комитетының 2019 ел
6 июнендәге № 1102 «Социаль наем
шартнамәләре һәм муниципаль
торак фонды карамагындагы торак
урыннарын наем шартнамәләре
буенча биләп торучылар өчен торак
урынын карап тоту һәм ремонтлауга,
шулай ук күпфатирлы торак йорт
белән идарә итү ысулын сайлап
алган, күпфатирлы йортлардагы
торак урыннарның милекчеләре өчен
торак урынын карап тоту һәм
ремонтлау турында гомуми
җыелышта түләү күләмен билгеләү
турында карар кабул итмәгән
милекчеләргә карата түләү күләмен
билгеләү турында»гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 маддәләре нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 6 июнендәге № 1102 «Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фонды карамагындагы торак урыннарын наем шартнамәләре буенча биләп торучылар өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлауга, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлап алган, күпфатирлы йортлардагы торак урыннарның милекчеләре өчен торак урынын карап тоту һәм ремонтлау турында гомуми җыелышта түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән милекчеләргә карата түләү күләмен билгеләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләме, дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча яллаучылар өчен торак урыннарын тоту өчен түләү

Зак. № 3063

күләме һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыны милекчеләре өчен торак урынын карап тотуга түләү күләме турында»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам».

2. Район башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталына урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Район башкарма комитеты җитәкчесе
вазифаларын башкаручы М.Н.Гирфанов